**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

БОЕРЫК

24.02.2016 Казан шәһәре № 104

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре вазыйфаларын башкаручы затларның вазыйфаи бурычларын үтәгән чакта яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендә кул куелган «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәтен башкаручы затлар һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгән чакта яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 650 номерлы карарын үтәү йөзеннән

боерам:

1. Әлеге «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре вазыйфаларын башкаручы затларның вазыйфаи бурычларын үтәгән чакта яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибе турында» Нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча секторга (Тайшибаева Л.Н.) Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен әлеге боерыкның 1 нче пункты белән расланган Нигезләмә белән таныштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз артымда калдырам.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре
һәм спорт министрлыгының
2016 елның 24 февралендә кул куелган
104 нче номерлы боерыгы тарафыннан расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАНЛЫК ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БАШКАРУЧЫ ЗАТЛАРНЫҢ ВАЗЫЙФАИ БУРЫЧЛАРЫН ҮТӘГӘН ЧАКТА ЯКЛАР КОНФЛИКТЫНА КИТЕРГӘН ЯКИ КИТЕРЕРГӘ МӨМКИН БУЛГАН ШӘХСИ КЫЗЫКСЫНУЛАРЫ КИЛЕП ЧЫГУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә тарафыннан Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) вазыйфаларын башкаручы затларның вазыйфаи бурычларын үтәгән чакта яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары килеп чыгу турында хәбәр итү тәртибен билгеләнә.

2. Гражданлык хезмәткәрләре Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнарына бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрына (алга таба – министрга) вазыйфаи бурычларны башкарганда яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулар килеп чыгу турында хәбәр итәргә, шулай ук яклар конфликтын булдырмау яки көйләү буенча чаралар күрергә тиеш.

Вазыйфаи бурычларны башкарганда яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулар килеп чыгу турында хәбәр 1 нче кушымтадагы форма буенча төзелгән белдерү кәгазе (алга таба – белдерү кәгазе) рәвешендә язмача формада рәсмиләштерелә.

3. Министр өч эш көне эчендә белдерү кәгазен алдан карау өчен коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Белдерү кәгазен алдан карау вакытында җаваплы затның белдерү кәгазе

җибәргән гражданлык хезмәткәреннән билгеләнгән тәртиптә язылган хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм кызыксындырган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә сораулар җибәрергә хокукы бар.

Сораулар җибәрелгән очракта белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яисә белдерү кәгазе кергән көннән башлап 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга да мөмкин, әмма 30 көннән дә артмаска тиеш.

5. Белдерү кәгазен алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат дәлилләнгән бәяләмә әзерли. Белдерү кәгазе, бәяләмә һәм алдан карау барышында алынган башка материаллар җаваплы зат белдерү кәгазен алган көннән башлап җиде эш көне эчендә Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә һәм яклар конфликтын көйләүгә таләпләрне саклау буенча Министрлык комиссиясенең (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Комиссия рәисе, аңа әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат кергәндә, 10 көн вакыт эчендә Комиссия утырышы көнен билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышы күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән 20 көнгә соңга калып билгеләнә алмый.

7. Комиссия белдерү кәгазьләрен, шулай ук бәяләмәләрне һәм башка материалларны карый һәм алар буенча, Министрлыкның 2016 елның 24 февралендә кабул ителгән 103 нче номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне саклау һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының яклар конфликтын көйләү буенча комиссиясе турында Нигезләмәгә туры китереп, карар кабул итә.

ТатарстанРеспубликасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре
вазыйфаларын башкаручы затларның
вазыйфаи бурычларын үтәгән чакта
яклар конфликтына китергән яки
китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксынулары килеп чыгу
турында хәбәр итү тәртибе турында
Нигезләмәгә
1 нче кушымта

___________________________________
(танышу турында билге)

Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре һәм спорт министрына
Министру по делам молодежи
и спорту

___________________________________

________________________________ дан
(Ф.И.А., биләгән вазыйфасы)
___________________________________
___________________________________

Вазыйфаи бурычларны башкарганда
яклар конфликтына китергән яки
китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксынулары килеп чыгу
турында

БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ

Минем вазыйфаи бурычларны башкарганда яклар конфликтына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым килеп чыгу турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксыну килеп чыгу өчен нигез булып торган хәлләр:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

Аларны башкарганда шәхси кызыксыну йогынты ясый яки йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи бурычлар: __________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Яклар конфликтын булдырмау яки көйләү буенча тәкъдим ителә торган чаралар:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Әлеге белдерү кәгазен карау вакытында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм яклар конфликтын көйләү буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга җыенам (җыенмыйм) (кирәклесе астына сызарга).

«___» ___________ 20__ ел _____________________________ _______________________

(белдерү кәгазе җибәрүче затның имзасы ) (имзаны аныклау)

ТатарстанРеспубликасы
Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре
вазыйфаларын башкаручы затларның
вазыйфаи бурычларын үтәгән чакта
яклар конфликтына китергән яки
китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксынулары килеп чыгу
турында хәбәр итү тәртибе турында
Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Вазыйфаи бурычларын башкарганда
яклар конфликтына китергән яки
китерергә мөмкин булган шәхси
кызыксынулары килеп чыгу
турында белдерү кәгазьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № | Белдерү кәгазе биргән гражданлык хезмәткәренең Ф.И.А.и. | Белдерү кәгазе биргән гражданлык хезмәткәренең вазыйфасы | Белдерү кәгазе кергән көн | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |